**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 июлендәге 2380 номерлы карары**

**«Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе»**
**ел саен уздырыла торган шәһәр конкурсын**
**үткәрү турында**

Тормышта катлаулы хәлгә юлыккан яисә социаль яктан куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны тәрбияләүдә ата-аналарга яисә законлы вәкилләргә ярдәм күрсәтүче, балигъ булмаганнар белән аларның җәмгыятькә каршы гамәлләрен, кабаттан җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр, җинаятьләр кылуларын кисәтү буенча шәхси профилактик эш алып баручы балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең абруен, статусын күтәрү максатыннан, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 декабрендәге 4773 номерлы «“2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау” муниципаль программасын раслау турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 28 апрелендәге 1471 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 декабрендәге 4773 номерлы “2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау” муниципаль программасын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә **карар бирәм**:

1. «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» ел саен уздырыла торган шәһәр конкурсы (алга таба – Конкурс) турында нигезләмәне әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.
2. Конкурсның җиңүчесен һәм приз яулаучыларын билгеләү буенча Конкурс комиссиясе составын әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә расларга.
3. Конкурсны оештыручы итеп Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратын билгеләргә.
4. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре

башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, В.В.Жаворонковка, Р.Р.Фәтхетдиновка Казан шәһәре районнарында конкурста катнашучыларны сайлап алу эшен оештырырга.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә (А.Р.Заһидуллина) Конкурсны үткәрүдә ярдәм күрсәтергә.

6. Әлеге максатлар өчен каралган Конкурсны оештыруга һәм бүләкләү тантанасын үткәрүгә 50,00 мең сум күләмендә чыгымнарны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының бюджет сметасы чикләрендә башкарырга.

7. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 июлендәге
2380 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**«Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе»**
**ел саен уздырыла торган шәһәр конкурсы турында**
**нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» ел саен уздырыла торган шәһәр конкурсы (алга таба – Конкурс) 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында»гы Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә.

1.2. Конкурс Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе инициативасы буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан үткәрелә.

1.3. Конкурсны оештыручы – Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1. Конкурс тормышта катлаулы хәлгә юлыккан яисә социаль яктан куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны тәрбияләүдә ата-аналарга яисә аларны алмаштыручы затларга ярдәм күрсәтүче, балигъ булмаганнар белән аларның җәмгыятькә каршы гамәлләрен, кабаттан җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр, җинаятьләр кылуларын кисәтү буенча шәхси профилактик эш алып баручы балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең абруен, статусын күтәрү максатыннан үткәрелә. Конкурс балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуын, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын кисәтү, гаиләне һәм балаларны яклау

буенча конституция нормаларын гамәлгә ашыру өлкәсендә социаль сәясәтне камилләштерүгә ярдәм итәчәк.

2.2. Конкурсның бурычлары:

1) балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең – үз вәкаләтләре чикләрендә балигъ булмаганнарны тәрбияләү һәм укыту бурычларын үтәүдә ата-аналарга яисә аларны алмаштыручы затларга ярдәм күрсәтергә тиешле тәрбия процессында катнашучыларның эшен стимуллаштыру;

2) социаль яктан куркыныч хәлдә яки тормышта катлаулы хәлдә калган балигъ булмаганнарны тәрбияләү өлкәсендә яңа методикаларны пропагандалау һәм тарату;

3) балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуларын һәм аларның хокук бозуларын профилактикалау системасының барлык органнары һәм учреждениеләре, хезмәт коллективлары, шулай ук балигъ булмаганнарның уку, эшләү яки яшәү урыны буенча иҗтимагый оешмаларның эшләрен берләштерү.

## III. Конкурста катнашучылар категорияләре һәм катнашу шартлары

Конкурста балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре – дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуларын һәм аларның хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре, хезмәт коллективлары һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре, хәрби хезмәткәрләр, педагогик хезмәткәрләр, тренерлар, мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре, пенсионерлар катнаша ала. Конкурста катнашучыларның яше – 21 яшь һәм аннан өлкәнрәк.

## IV. Конкурсны үткәрү вакытлары һәм тәртибе

4.1. Конкурс агымдагы елның 14 июленнән 31 июленә кадәр өч этапта үткәрелә:

- беренче этап: 14 июльдән 21 июльгә кадәр – Конкурста катнашучылар тарафыннан Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин, Киров һәм Мәскәү, Совет районнарының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренә гаризалар һәм материаллар тапшыру;

- икенче этап (читтән торып): 22 июльдән 24 июльгә кадәр – Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин, Киров һәм

Мәскәү, Совет районнарының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан шәһәр Конкурсына катнашучыларны сайлау һәм материалларны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә җибәрү;

- өченче этап (турыдан-туры катнашу): 25 июльдән 31 июльгә кадәр – шәһәр Конкурсын үткәрү.

4.2. Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктчасында билгеләнгән вакыт эчендә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча гариза;

- әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымтадагы форма буенча Конкурста катнашучы турында анкета-тәкъдимнамә;

- әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымтадагы форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм тапшыруга ризалык;

- Конкурсның шәһәр этабында катнашучы портфолиосы.

4.3. Барлык материаллар рус телендә Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсенең электрон почтасына электрон рәвештә җибәрелә: social.kzn@tatar.ru. Хатның темасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссиясенең исемен күрсәтергә кирәк.

4.4. Конкурста катнашуга гаризаны кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- Конкурста катнашучының әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

- катнашучы тарафыннан тапшырылган гаризаның һәм документларның әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктчасында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- катнашучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

- катнашучының гаризаны әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктчасында билгеләнгән вакыт чыкканнан соң бирүе.

## V. Конкурс комиссиясен төзү һәм эшләү тәртибе

5.1. Эшләрне карап тикшерү өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкилләреннән Конкурс комиссиясе оештырыла.

5.2. Конкурс комиссиясе составы барлыгы 11 кешедән тора. Аңа комиссия

рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары керә.

5.2.1. Конкурс комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, шулай ук комиссия утырышларын үткәрү өчен җавап бирә.

5.2.2. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазифаларын башкара.

5.2.3. Конкурс комиссиясе сәркатибе Конкурс комиссиясе эшен, шул исәптән гаризалар исемлеген формалаштыруны, карарлар төзүне, комиссия утырышы беркетмәсен алып баруны тәэмин итә.

5.3. Конкурс комиссиясе составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.4. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүне Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башкара.

5.5. Конкурста катнашучыларга бәя бирү өчен Конкурс комиссиясе:

- катнашучы турында мәгълүмат булган анкеталарны карап тикшерә;
- һәр катнашучының эшен гадел бәяли;
- һәр катнашучының рейтингыннан чыгып, Конкурска нәтиҗә ясый.

5.6. Конкурста җиңүчеләрне һәм приз яулаучыларны ачыклаганда, тавышлар саны тигез булса, Конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

5.7. Конкурс комиссиясе үз көче белән һәм үз вәкаләтләре кысаларында тапшырылган материаллардагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә.

5.8. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, Конкурс комиссиясе утырышы башланганчы, бу хакта Конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы Конкурс комиссиясе утырышында катнашмый.

5.9. Конкурс комиссиясе утырышы, анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

5.10. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелми.

## VI. Конкурсның эчтәлеге һәм Конкурс биремнәрен бәяләү

6.1. Конкурс эчтәлеге:

1) «Мин – балигъ булмаган затның җәмәгать тәрбиячесе» визит

карточкасы. Аны тәкъдим итү барышында катнашучы җәмәгать тәрбиячеләре институтына, үзенең тәрбияләнүчеләренә һәм хезмәттәшләренә, гаиләсенә мөнәсәбәтен, тормышындагы мөһим кыйммәтләрне һәм үз эшенең нәтиҗәләрен ачарга тиеш, регламент – 5 минут.

Турыдан-туры чыгыш ясаган вакытта тәкъдим итү өчен заманча техник чаралар кулланыла. Чыгыш вакытында кулланыла торган видеоматериаллар һәм башка төр тәкъдим итү чаралары катнашучының чыгышын тулысынча кабатларга тиеш түгел.

Визит карточкасын бәяләү буенча критерийлар (максималь баллар саны – 30):

- тәкъдим ителә торган тәҗрибәнең әйдәп баручы идеясе (максат ачык һәм конкрет формалаштырылган, дөрес нигезләнгән, чынбарлыкка һәм тәрбияләнүченең яшь үзенчәлекләренә туры килә, балигъ булмаганнарга карата дөрес билгеләнгән һәм диагностикаланган) – 0 дән 5 баллга кадәр;
- тәрбия эшчәнлеге эчтәлеген дәлилләп аңлату (юнәлешләр, формалар, ысуллар куелган максатлардан чыгып сайланган; дөрес нигезләнгән; тәрбияви әһәмияткә ия, системалы характерда; оригинальлек һәм авторлык мөнәсәбәте) – 0 дән 5 баллга кадәр;
- үз эшчәнлеге нәтиҗәлелеген контрольдә тоту формаларын һәм ысулларны ачу – 0 дән 5 баллга кадәр;
- алынган нәтиҗәләр (реаль; куелган максатларга туры килә; аларны билгеләү ысуллары дөрес) – 0 дән 5 баллга кадәр;
- тәрбияче эшендә булган проблемалар (дөрес формалаштырылган; тәрбиянең үз эшчәнлеген анализлый белүе, каршылыкларны һәм перспективаларны күрә белүе турында күзаллау бирә) – 0 дән 5 баллга кадәр;
- регламентны саклау – 0 дән 5 баллга кадәр;

2) балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә норматив-хокукый база нигезләрен белү буенча әңгәмә (максималь балл – 50):

- тапкырлык - 0 дән 10 баллга кадәр;
- фикерләү оригинальлеге – 0 дән 10 баллга кадәр;
- оештыру сәләте – 0 дән 10 баллга кадәр;
- иҗади алым – 0 дән 10 баллга кадәр;
- балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге законнарны белү – 0 дән 10 баллга кадәр.

6.2. Конкурс комиссиясенең Конкурска нәтиҗәләр ясау турындагы карары Конкурс уздырылган көнне күпчелек тавыш белән кабул ителә, Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан расланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Конкурс комиссиясе әгъзасы Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, ул беркетмәгә үзенең аерым фикерен кертә.

6.3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе, 2026 елның 10 августыннан да соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталындагы яңалыклар бүлегендә (https://kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/upravlenie-sotsialnoy-politiki/novosti/) Конкурс нәтиҗәләрен бастырып чыгара.

## VII. Конкурс җиңүчесен һәм приз яулаучыларын бүләкләү

7.1. Конкурс җиңүчесе итеп иң күп балл җыйган Конкурста катнашучы таныла. Конкурста призлар яулаучы булып, Конкурста катнашып, 1, 2, 3 урыннарны алучылар санала.

7.2. Конкурста җиңүче һәм призлар яулаучылар турында карарны Конкурс комиссиясе гади күпчелек тавыш белән кабул итә. Конкурс комиссиясе утырышында расланган составның кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

7.3. Конкурска нәтиҗәләр ясау, Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү һәм җиңүчене һәм приз яулаучыларны бүләкләү агымдагы елның 31 июлендә, Конкурс уздырылган көнне гамәлгә ашырыла.

7.4. Конкурс комиссиясе беркетмәсе Конкурста җиңүчене һәм приз яулаучыларны бүләкләү өчен нигез булып тора.

7.5. Конкурста җиңүче һәм приз яулаучылар билгеләнгән үрнәктәге дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнәләр. Конкурста җиңү һәм приз яулауга ирешмәгән катнашучыларга Конкурста катнашу турында грамоталар тапшырыла.

«Балигъ булмаганнарның иң яхшы
җәмәгать тәрбиячесе» ел саен
уздырыла торган шәһәр конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**«Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» ел саен уздырыла торган шәһәр конкурсында катнашуга гариза**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Конкурста катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) | |
| 2 | Туу датасы | |
| 3 | Эш урыны, вазифасы | |
| 4 | Эш урыны адресы, телефон, электрон почта | |
| 5 | Өй адресы, телефон, шәхси электрон почтасы | |
| 6 | Белеме турында мәгълүмат | |
| 7 | Җәмәгать тәрбиячесе буларак эш стажы | |
| 8 | Дәүләт һәм тармак бүләкләре | |
| 9 | Өстәмә рәвештә хәбәр итәргә кирәк дип саный торган мәгълүмат | |

«Балигъ булмаганнарның иң яхшы
җәмәгать тәрбиячесе» ел саен
уздырыла торган шәһәр конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Конкурста катнашучы турында анкета-тәкъдимнамә**

Казан шәһәренең__________________________________________ районы.
Тормыш кредосы _________________________________________________.

**Конкурста катнашучы турында мәгълүмат**:

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)____________
_______________________________________________________________________.
2. Туу датасы ___________________________________________________________.
3. Эш урыны, вазифа_____________________________________________________.
4. Эш урыны адресы, телефон_______________________________________________
_______________________________________________________________________,
электрон почта__________________________________________________________.
5. Өй адресы, телефон____________________________________________________
_______________________________________________________________________,
электрон почта__________________________________________________________.
6. Белеме турында мәгълүмат ___________________________________________
_______________________________________________________________________.
7. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячесе булып эшләү стажы____________________________________________________________________.
8. Дәүләт һәм тармак бүләкләре
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________.
9. Үзегез турында өстәмә рәвештә тагын нинди мәгълүматлар бирергә кирәк дип санайсыз
_______________________________________________________________________.

«Балигъ булмаганнарның иң яхшы
җәмәгать тәрбиячесе» ел саен
уздырыла торган шәһәр конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм тапшыруга ризалык**

Мин, _______________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы таләпләре нигезендә ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә Татарстан Республикасының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә фамилияне, исемне, әтиемнең исемен (булган очракта), эш урынын һәм адресын, вазифаны, электрон почта адресын, элемтә өчен телефон номерын, өй адресын, белем, гыйльми исем, гыйльми дәрәҗә турында белешмәләрне үз эченә алган шәхси мәгълүматларымны, автоматлаштырылган режимда, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртүгә (җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, шәхси үзенчәлекләрен бетерүне, тыюны, бетерүне, юкка чыгаруны, тапшыруны (таратуны, бирүне, файдалану өчен рөхсәтне) кертеп), тиешле мәгълүмат белән танышып, аңлы рәвештә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык аны имзалаган көннән гамәлгә керә, вакыты билгеләнмәгән чор дәвамында гамәлдә була һәм 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон (гамәлдәге редакциядә) белән билгеләнгән тәртиптә язмача гариза нигезендә кире алынырга мөмкин.

Элемтә өчен телефон номер(-лар)ы_______________________________.

______________________________ ______________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының имзасы) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме [соңгысы – булган очракта])

_________________________
(дата)

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 июлендәге
2380 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**«Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе»**
**ел саен уздырыла торган шәһәр конкурсында**
**җиңүчене һәм приз яулаучыларны билгеләү буенча**
**Конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| А.И. Абзалов | Конкурс комиссиясе рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| И.П.Смирнова | Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башлыгы |
| Н.А.Кәримова | Конкурс комиссиясе сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль үсеш идарәсендә социаль үсеш һәм гаилә иминлеге бүлеге башлыгы |

**Комиссия әгъзалары**:

| | |
|---|---|
| И.А.Ризванов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| А.Р.Заһидуллина | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| Д.И.Хвостиков | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе |
| Л.З.Гарипов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты рәисе |
| Т.Ю.Агафетова | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы урынбасары |

| | |
|---|---|
| О.А.Дроздецкая | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы урынбасары |
| Д.В.Сугоняко | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы урынбасары |
| А.И.Хәмзина | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы урынбасары |